ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм “Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы беренче өлешенең беренче җөмләсенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 1; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 4) “яисә “Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы”нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару)” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның беренче өлешенә “яисә “Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы”нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару)” сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:

а) беренче өлештә “рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш” сүзләре алдыннан “Республика Татарстан” һәм “Ватаным Татарстан” газеталарында” сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә “рәсми рәвештә бастырып чыгарыла” сүзләре алдыннан “Республика Татарстан” һәм “Ватаным Татарстан” газеталарында” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле дүртенче өлеш өстәргә:

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын “Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы”нда (www.pravo.gov.ru) рәсми бастырып чыгару аларга имза салган көннән 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.”;

3) 6 статьяның беренче һәм өченче өлешләрендә “Республика Татарстан” һәм “Ватаным Татарстан” газеталарында” сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон 2014 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 24 июле
№ 73-ТРЗ